ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

# КАРАР

« 24 » март 2021 ел №  9

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2021 елның 18 мартындагы Шушмабаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июнендәге 123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

1.1. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында:

-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:09:130406:37 кадастр номерлы 598 400 кв. м мәйданлы җир кишәрлеге өчен СХ1 авыл хуҗалыгы җирләре территориаль зонасыннан авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары территориаль зонасына үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын (1 нче кушымта) билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1Б йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, 45 йорт адресы буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны үтәүне тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

*Арча муниципаль районы*
*Шушмабаш авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*24.03.2021ел, № 9*
*карарына кушымта*

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүнең якынча сроклары**

| № | Шушмабаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне уздыру срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен оештыру. | 2021 елның I-II кварталлары |
| 2. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү һәм килештерү. | 2021 елның II кварталы |
| 2.1. | Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволарның кисәтүләренә шәрехләр әзерләү | 2021 елның II кварталы |
| 3. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты турында фикер алышу. Гавами тыңлаулар үткәрү. | 2021 елның II кварталы |
| 3.1. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын һәм аңа мәҗбүри кушымталарны (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын раслау яки кире кагу һәм кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, аны эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итү өчен Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгына җибәрү | 2021 елның II кварталы |